Кукмара муниципаль районы
Березняк авыл җирлеге Советы

# КАРАР

12 март 2020 ел № 5

Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль милкендәге һәм өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән мөлкәт белән эш итү (җир кишәрлекләрен дә кертеп) буенча Березняк авыл Башкарма комитетының вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Березняк авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Березняк авыл Башкарма Комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль милкендәге һәм өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән мөлкәт белән эш итү (җир кишәрлекләрен дә кертеп) буенча;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (www.kukmor.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль милекендәге күчемсез милек объектлары турында, кече эшмәкәрлек субъектларына тапшыру һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән мөлкәтне күрсәтеп, мәгълүмат бастыру буенча.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, Кукмара

муниципаль районы Советы Березняк авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең бюджеты турында карарга үзгәрешләр кертү турында карар проектын бюджет законнары нигезендә эшләргә һәм карау өчен тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына, Березняк авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Березняк авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Шәрипов